**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Граждан оборонасы өлкәсендә федераль законнарга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы һәм 2016 елның 19 гыйнварындагы ПУ-18 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.5 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4.19 пункты өстәргә:

«4.19. Граждан оборонасы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл иткәндә, шулай ук граждан оборонасы өлкәсендә карарлар кабул итүдә мәгълүмати ярдәм чараларын гамәлгә ашырганда граждан оборонасына идарә, граждан оборонасы көчләренә һәм чараларына идарә органнары эшчәнлеген координацияләүне, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның мәгълүмати бәйләнешләрен оештыруны тәэмин итүне федераль законнар нигезендә Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы билгеләгән тәртиптә «Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Кризислы хәлләрдә идарә үзәге» федераль казна учреждениесенең гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 ел, 04 июнь
№ ПУ-502